**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

« 12 » декабрь 2022г. с. Тюлячи № 274

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 сентябрендәге 186 номерлы «Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскурантын раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә,

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 сентябрендәге 186 номерлы «Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскурантын раслау турында» боерыгына (10.10.2022 № 230 боерыгы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән боерык белән расланган «Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскурантында «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакырылган гражданнарның гаиләләреннән һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләреннән булган балалар» сүзләрен «махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев